СОВЕТ МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

27.07.2026 с.Майдан № 13 – 66

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сораштыру билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советының 29.03.2013 ел № 27 – 145 карары белән (24.05.2021 ел № 8 – 53 карары үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге территориясендә, «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 13 нче филиалы Урман участогы авыл клубын бетерү мәсьәләсе буенча халык фикерен ачыклау максатында, исемле тавыш бирү рәвешендә гражданнардан сораштыру үткәрүне билгеләргә.
2. Билгеләргә:

- сораштыруны үткәрү датасы һәм вакыты - 07.08.2026 ел 8.00 дән 20.00 гә кадәр;

- сораштыру үткәрү урыны – Мәйдан авыл җирлегендә яшәүчеләрне теркәү урыны буенча

3. Сораштыру исемлекләре буенча исемләп тавыш бирү үткәрергә
4. Гражданнардан сораштыру үткәргәндә сораштыру исемлегенә кертү өчен түбәндәге сорауның формулировкасын расларга: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 13 нче филиалы Урман участогы авыл клубын бетерүгә ризамы?"
5. Сораштыру үткәрү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).
6. Сораштыру исемлегенең формасын һәм текстын расларга (2 нче кушымта).
7. Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегендә 170 кешедән торган сораштыруда катнашучыларның минималь санын билгеләргә.
8. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга.

Совет рәисе урынбасары,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы урынбасары В.Е. Сафонова

Мәйдан авыл җирлеге Советының<br>27.07.2026 ел, №13-66 карарына<br>1 нче кушымта

Гражданнардан сораштыру үткәрү

КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

1. Файзрахманова Зиля Накифовна –Мәйдан авыл җирлеге башлыгы

2.Коновалова Елена Юрьевна – Мәйдан авыл җирлеге секретаре

3.Сафонова Валентина Евгеньевна – Мәйдан авыл җирлеге депутаты

4.Яманова Наталья Викторовна – Мәйдан авыл җирлеге депутаты

5.Малафеева Валентина Ивановна – Мәйдан авыл җирлеге волонтеры

Мәйдан авыл җирлеге Советының
27.07.2026 ел, №13-66 карарына
2 нче кушымта

СОРАШТЫРУ ИСЕМЛЕГЕ

Сораштыру үткәрелә торган сорауны формулировкалау: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 33 нче филиалы Урман участогы авыл клубын бетерүгә ризамы?"

| Фамилия, исеме, атасы исеме | Туган көне, ае һәм елы | Яшәү урынының адресы | Дата | Тавыш бирү тамгасы | | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | РИЗА | КАРШЫ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |

Комиссия рәисе________________________________________ ____________
(имза) (имзаның расшифровкасы) (дата)

Комиссия секретаре ____________ ____________________ ____________
(имза) (имзаның расшифровкасы) (дата)